КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июль г.Казань № 582

Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карары белән расланган «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасына теркәлгән 8 нче кушымтада китерелгән Россия Федерациясе субъектының инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру буенча бертип программасы нигезендә эшләнгән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына кертелгән чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен расларга.
2. Бу карарның гамәле 2019 елның 30 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 июль, 582 нче
карары белән расланды

# Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган, инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән «2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) тормышка ашыруга Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү механизмын (алга таба – Кагыйдәләр) билгели.

2. Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын үз эченә алган дәүләт программасын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләр (алга таба – федераль бюджеттан субсидия) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бу Кагыйдәләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш итүчеләр – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Акча белән баш эш итүчеләр).

4. Федераль бюджеттан субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына ачылган шәхси счетка керә.

5. Федераль бюджеттан субсидияләрне тоту Акча белән баш эш итүчеләр тарафыннан Казначылыкта ачылган шәхси счетлар аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы биш эш көне эчендә, финанслауның иң чик күләмнәре Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан ирештерелгәннән соң, финанслауның иң чик күләмнәрен Акча белән баш эш итүчеләргә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан

Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары чикләрендә ирештерә.

7. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән акча исәбеннән Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт автоном һәм бюджет оешмаларына (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә субсидия бирүне гамәлгә ашыра һәм финанслауның иң чик күләмнәрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесенә ирештерүне тәэмин итә.

8. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесенең шәхси счетыннан акча күчерү «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контрактлары буенча гамәлгә ашырыла.

9. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы түбәндәгеләрне Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертә:

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 10 гыйнварына кадәр, федераль бюджеттан субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10ысыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (федераль бюджеттан субсидия бирү аларны финанслашу максаты булып тора) турындагы хисапны.

10. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе түбәндәгеләрне Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертә:

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 9 гыйнварына кадәр, федераль бюджеттан субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 8еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (федераль бюджеттан субсидия бирү аларны финанслашу максаты булып тора) турындагы хисапны.

11. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы түбәндәгеләрне Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертә:

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 15 гыйнварына кадәр, федераль бюджеттан субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү

турындагы хисапны «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән дәүләт мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (федераль бюджеттан субсидия бирү аларны финанслашу максаты булып тора) турындагы хисапны «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән дәүләт мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә.

12. Бу Кагыйдәләрнең 9 – 11 нче пунктларында күрсәтелгән хисаплар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 269н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүнең бертип формасына теркәлгән 10 нчы һәм 11 нче кушытмаларында китерелгән форма буенча бирелә.

13. Агымдагы финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешләрен федераль бюджет керемено Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше федераль бюджет керемено күчерелмәгән очракта, әлеге акча федераль бюджет керемено Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

14. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм федераль бюджеттан субсидияләрне максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. Федераль бюджеттан бирелгән субсидиядән максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашырыла.